Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы 18 нче катнаш балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү бюджет учреждениясе

**Уен – кызыксыну һәм белемгә омтылу утын кабыза торган очкын ул.**
**В.А.Сухомлинский.**

Гыйльметдинова Миләүшә Рәшит кызы,
югары квалификация категорияле
татар теле тәрбиячесе

## Дидактик уеннар

Дидактик уеннар - балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе.

Уен вакытында бала предметларны чагыштырырга, охшаш һәм аерым якларын ачыкларга өйрәнә; предметларның үзенчәлекләре: төсе, зурлыгы, формасы, сыйфаты белән таныша. Дидактик уеннар тәрбия чарасы буларак та отышлы, чөнки алар барышында күмәклек, дуслык, игътибарлылык, ярдәмләшү кебек матур сыйфатлар, шулай ук бала күңелендә туган телне, халкыбызның үткәнен, гореф-гадәт, йолаларын ихтирам итү, эстетик зәвык тәрбияли, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә.

Уен өчен уңайлы шартлар тудыру игътибар үзәгендә булырга тиеш. Кирәк-яраклар, кулланмалар алдан ук әзерләп куела. Кулланыла торган уенчыклар, җиһазлар балаларның игътибарын җәлеп итә торган ачык төстә, матур булсын. Аларны әзерләү, аннары тәртипләп урнаштыру эшләренә балаларны катнаштырырга кирәк. Алар бу вакытта пөхтәлеккә, чисталыкка өйрәнә, әйберләрне саклап тотарга күнегә.

Дидактик уеннарның балаларга акыл тәрбиясе бирүдә роле зур. Уен вакытында баланың сөйләме үсә, сүз байлыгы арта. Уен вакытында бала телне өйрәнү бурычын куймый, ул уйный, уен өчен аңа бу сүзләрне белү кирәк. Күп тапкыр ишетеп балада аралашу өчен кирәк булган телнең образы барлыкка килә.



# Уен – лото “Өч аю”

**Уен кагыйдәләре:**

**1 ысул “Үз парын тап”.** Балага төрле зурлыктагы аю рәсемнәре бирелә (әти, әни, малай). Бала һәр аюга зурлыгы буенча туры килгән предмет рәсемнәрен (урындык, кашык, тәлинкә, чынаяк, караваt) бирә.

**Сөйләм үрнәге:** -Зур аю (әти), мә зур кашык.

-Кечкенә аю (малай), мә кечкенә урындык.

**2 ысул “Рәсемне җый”.** Бала өлеш буенча тулы рәсемне җыярга тиеш. Таныш сүзләрне әйтә.

**3 ысул “Бу йортта кем яши?”.** Сюжетлы рәсем буенча балалар билгене, хәрәкәтне белдергән сүзләрне кулланып җөмләләр төзиләр.

**Сөйләм үрнәге:** Зур аю. Кечкенә аю утыра. Яшел урындык. Әни яшел урындыкта утыра.

**4 ысул “Сыйла”.** Балалар аюларны ботка, чәй белән сыйлыйлар.

**Сөйләм үрнәге:** Зур аю (әти), мә ботка. Ботка тәмле.Зур аю (әти), ботка аша.



# “Сыйла” уены

**Уен кагыйдәләре:**

**1 ысул “Нәрсә?”.** Өстәлдә ашамлыклар, җиләк-җимешләр, яшелчәләр сурәтләнгән рәсемнәр ята. Балалар чиратлашып өстәл янына килеп үзләренә охшаган рәсемне алалар һәм нәрсә икәнен әйтәләр.

**2 ысул “Сыйла”.** Бала алган рәсем белән Капкорсакны сыйлый.

**Сөйләм үрнәге:** - Мә, алма. Алма кызыл. Алма аша.

- Мә, алма аша. Алма тәмле.



# “Төсләр дөньясында” уены

**Уен кагыйдәләре:**

**1 ысул “Нинди?”.** Балаларга төрле төстәге (кызыл, яшел, сары, зәңгәр, ак, кара) бөкеләр беркетелгән панно күрсәтелә. Балалар чиратлап бөкеләрнең төсләрен әйтәләр.

**2 ысул “Нинди төс юк?”.** Тәрбияче балалар күрмәгәндә бер бөкене борып ала. Кайсы төстәге бөкенең юклыгы ачыклана һәм үз урынына борып куела.

**3 ысул “Боерыкны үтә!”.** Бер бала командир итеп сайлана. Командир иптәшенә боерык бирә. Мәсәлән: “Кызыл!”. Бала кызыл төстәге бөкене таба һәм борып алып нинди төстә икәнен әйтә. Бөкеләр алып бетерелгәннән соң, уен шушы тәртиптә бөкеләрне кире урыннарына борып кую белән дәвам ителә.

